


*Дәреснең темасы: Минем гаиләм*
*(2 нче сыйныф, татар төркеме)*

# Бу нинди хәреф?

А а



# Бу нәрсә?

# Бу нинди хәреф?

Ә ә



# Бу кем?

# Бу нинди хәреф?

Ө ө

Бу ничә?





Булышучыларыбызга рәхмәт сүзләре языйк!

Резедә Вәлиеваның “Дәү әни” хикәясе



- Чандыр – ябык
- Көмеш – аксыл төстәге металл
- Мәзәк – кызыклы хәл
- Җемелдәп торган – сверкающий
- Ефәк – шёлковый
- Юка – тонкий
- Чук – бизәү өчен тагылган җепләр



# Дәү әни.

Гөлнурларга дәү әнисе килде. Бик ярата Гөлнур дәү әнисен. Кечкенә чагында, әле мәктәпкә дә йөрмәгәндә, Гөлнур аларга бик еш бара иде. Еш бара, барган саен, озак-озак итеп торып кайта иде.

Дәү әнисе бик тә әйбәт Гөлнурның. Чандыр гына, җиңел гәүдәле. Көмеш кебек ап-ак чәчләрен һәр иртәне әйбәтләп тарый да яулык астына яшереп куя. Чәчләре ап-ак, ә кашлары чем-кара аның. Куллары, кечкенә генәбулса да, бик нык. Шуңа күрә бөтен нәрсәне үзе эшләргә ярата да торгандыр әле ул.

Бер дә тавышын күтәрми Гөлнурның дәү әнисе. Һәрвакыт тыныч кына, җайлы гына итеп сөйләшә. Аннары бик күп әкиятләр белә, төрле-төрле мәзәкләр сөйли.

Бу юлы бигрәк матур итеп киенеп килгән ул. Өстендә - җемелдәп торган яшел чәчәкле ефәк күлмәк, кара яшел йон кофта. Аякларында – атлаган саен шыгыр-шыгыр итеп торган йомшак читекләр. Чигүле ап-ак юка яулык өстенә чуклы ак челтәр шәл япкан.

Резедә Вәлиевадан

# Күзләргә зарядка

# Дәү әни.

Гөлнурларга дәү әнисе килде. Бик ярата Гөлнур дәү әнисен. Кечкенә чагында, әле мәктәпкә дә йөрмәгәндә, Гөлнур аларга бик еш бара иде. Еш бара, барган саен, озак-озак итеп торып кайта иде.

Дәү әнисе бик тә әйбәт Гөлнурның. Чандыр гына, җиңел гәүдәле. Көмеш кебек ап-ак чәчләрен һәр иртәне әйбәтләп тарый да яулык астына яшереп куя. Чәчләре ап-ак, ә кашлары чем-кара аның. Куллары, кечкенә генәбулса да, бик нык. Шуңа күрә бөтен нәрсәне үзе эшләргә ярата да торгандыр әле ул.

Бер дә тавышын күтәрми Гөлнурның дәү әнисе. Һәрвакыт тыныч кына, җайлы гына итеп сөйләшә. Аннары бик күп әкиятләр белә, төрле-төрле мәзәкләр сөйли.

Бу юлы бигрәк матур итеп киенеп килгән ул. Өстендә - җемелдәп торган яшел чәчәкле ефәк күлмәк, кара яшел йон кофта. Аякларында – атлаган саен шыгыр-шыгыр итеп торган йомшак читекләр. Чигүле ап-ак юка яулык өстенә чуклы ак челтәр шәл япкан.

Резедә Вәлиевадан

# Ял иту



- Гөлнурларга кем килгән? Аның чәчләре, кашлары нинди төстә?



- Гөлнурның дәү әнисе ничек киенгән?



- Үзеңнең дәү әниең турында сөйлә.



1. Сез нәрсә күрдегез?
2. Сез моның турында нәрсә уйлыйсыз?
3. Сезне шулай уйларга нәрсә мәҗбүр итте?


игрушки
из
ДЕРЕВА

- Ошады!
- Ошамады!





# Өй эше

- 1 нче номерлы укучыларга:
- Үзегезнең әбиләрегез, дәү әниләрегез турында кечкенә хикәя язып килерсез.
- 2 нче номерлы укучыларга:
- Әниегез турында кечкенә хикәя язарга.
- 3 нче һәм 4 нче номерлы укучыларга:
- “Минем гаиләм” дигән рәсем ясарга.

Дәрес тәмам!

Сау булыгыз!